**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Кәркәүч урта гомуми белем бирү мәктәбе**

# Шушы яктан, шушы туфрактан без

**Кукмара**

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Кәркәүч урта гомуми белем бирү мәктәбе**

# Шушы яктан, шушы туфрактан без

**Кукмара**

Тормыш безгә биргән гомер хакын
Без артыгы белән түләрбез.

**9 нчы укучы**. Рәхмәт сиңа мәхәмәтең өчен, Тормыш,
Соңгы көнең белән янамадың.
Үткәннәрне тезеп күрсәтсәң дә арттан,
Калганнарын алга тезеп санамадың.

**10 нчы укучы.** Кайда ул көч, кайда сихри куәт,
Бәйрәм булып җиргә килерлек?
Ваемсызга вөҗдан, намуссызга зиндан,
Ә вәхшигә үлем бирерлек?

**11 нче укучы.** “Шундый вакыт... дибез; Вакыт имеш.
Аның бездә нинди эше бар?
Кешелекне саклап кала җирдә
Кеше булып калган кешеләр.

“ Ашкын, кешем” җыры (Л.Хәйретдинова музыкасы, Зөлфәт сүзләре) башкарыла.

Кичәнең икенче өлешендә укучылар шагыйрьнең “Гөлбикә”, “Шук малай”, “Кайсыбыз хаклы”, “Тәмле китап”, “Булышчы”, “Мактану” шигырьләрен сәнгатьле итеп яттан сөйләделәр.

.



**Автор:** Хакова Р. Г. Кәркәүч урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Рецензентлар:** Ганиева Диләрә Хәкимовна, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының мәгълүмати-методик үзәге баш белгече

Ахметзанов Илгиз Агмалович, Кәркәүч урта гомуми белем бирү мәктәбе директоры

Әдәби – музыкаль кичәләр 5 - 9 сыйныф

Җыентыкта мәктәптә бәйрәмнәр, кичәләр уздырганда файдалану өчен әдәби- музыкаль композицияләр тупланды.

**Шушы яктан, шушы туфрактан без.**
Мөгаллимнәргә, методистларга, тәрбиячеләргә методик кулланма булыр, дип ышанабыз.

## Аңлатма язуы

Мәктәптә үткәрелә торган дәрестән тыш эшләр тәрбия эшен оештыруда мөһим роль уйный.Ул белем һәм тәрбия бирүдә бердәм процесс буларак, дәресләрнең дәвамы итеп бәяләнә. Әмма дәрестән аермалы буларак сыйныфтан тыш эшләрне оештыруда түбәндәге юнәлешләр күз алдында тотыла:

1) укучыларда фәнгә карата кызыксыну, белемгә омтылыш тәрбияләү;
2) фән буенча алган белемнәрне тирәнәйтү һәм дөньяга караш тәрбияләү;
3) алган белемнәргә нигезләнеп укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү.

Укучыларга җирле –төбәк күрсәткечләрен өйрәтү, якташ язучылар иҗатына таянып, үз төбәгең, аның күренекле шәхесләре белән горурлану хисләре тәрбияләүдә сыйныфтан тыш эшләрнең әһәмияте зур. Укучыларда әдәбиятны өйрәнүгә кызыксыну уята, аларның мөстәкыйльлеген һәм инициативасын үстерә, туган телебезнең байлыгын, нәфислеген сиземләүгә ярдәм итә андый эшләр. Н. Островский, Ф. Яруллиннар кебек көчле рухлы, язмыш авырлыкларына бирешми яшәүче якташ – шагыйребез Р.Шәриповның, композитор Фасил Әхмәтнең тормыш һәм иҗат юлына багышланган әдәби композиция шушы максатны күздә тотып төзелде.

Дәрестән тыш эшләр укучыларда белем алуга һәм фәнгә карата кызыксыну уята, балаларга күп мәгълүмат бирә, фән буенча белемнәрен тирәнәйтә, сүзгә сак караш, сөйләм осталыгы тәрбияли.



Илтсәләр дә безне еракларга
Замананың кызу юллары,
Онытмагыз тауны, онытмагыз
Чокырчаның моңлы уллары.

**4 нче укучы**. Ни әйтсәң дә, туган моңнар белән
Чит җирләрнең ерак арасы.
Җырлаганда елап үскән, мин бит
Авылымның газиз баласы.

**5 нче укучы**. Алып китте дулап, адаштырды
Вакыйгалар, еллар бураны.
Күпме юллар белән тотташтырды
Кукмараның үзәк урамы
Баскычлардан йөгереп төшкән идем
Язмышыма сагыш юрамый,
Еллар узгач, урап кайттым сиңа
Кукмараның үзәк урамы.

Җыр “Кукмара”( Г. Зәйнәшева сүзләре, М. Имашев көе.)

**6 нчы укучы**. Сүндерде җил өмет утын,
Каерды да кулымны
Әкрен генә эзләп керәм
Йөгереп чыккан юлымны.
Яктыртып булмый дөньяны
Тормыш ага да ага.
Өмет кабына да сүнә
Кемдер тәрәзә кага.

**7 нче укучы**. Сыгылып, егылып калмадым,
Язмышым үземнең кулымда.
Бәхетем – үзгәрмим һаман да,
Уйларым мәхәббәт турында.

**8 нче укучы**. Егылсак та әле көрәшербез,
Кирәк икән – басып үләрбез.

Үттек биреп кулны кулларга.

7 **нче укучы**. Каршы йортта утлар сүнә,
Яңа тәүлек башлана.
Тик бер генә тәрәзәдә
Сүнми һаман, ут яна.
Әллә инде бер яшь шагыйрь
Вакыт узганын сизми,
Елый – елый шигырь яза,
Ут яндырып сүз эзли.

**1 алып баручы.** Рәниф кулына чынлап торып каләм ала. Дөрес, моңа кадәр дә шигырьләр язгалый ул. Ниһаять, шигърият дигән кошчык күңелен чукый-чукый да килеп тә чыга.

**1 нче укучы**. Читлек тар шул. Күңел уты
Сыймый кысан ояга.
Кайчак шигъри очкын булып,
Очып чыга дөньяга.

**2 нче укучы**. Туган илнең бер ягыннан бер ягына
Куды язмыш инде күпме еллар элек.
Гомеремнең бер кисәге калган жирдә.
Җанымның да бер өлеше калды кебек.

**2 алып баручы**. Шагыйрь Казанда яши башлый. Туган ягыннан читтә яшәсә дә, ижатында туган як табигате, аның кешеләре, гүзәл Кукмара якларының сурәтле образы кызыл җеп булып сузылып бара.

Жыр: “ Шушы яктан, шушы туфрактан без”.

**3 нче укучы**. Якташларны читтә күп очратым,
Һәркем безнең тауны сагына.
Мин дә кайтып сихәт алдым бераз
Кукмараның таулы ягында.



Дәрестән тыш эшләр, нигездә, белем һәм тәрбия бирү максатыннан чыгып эшләнә. Ул дәреснең дәвамы буларак укучының яшь үзенчәлекләренә туры китереп үткәрелә. Дәрестән тыш эшне оештыруда, җирле региональ компонентлар киң урын ала.

Бу методик кулланмада югары сыйныфлар өчен әдәби – музыкаль композицияләр бирелде. Һәр ижади эшләүче укытучы аларны үзгәртә ала. Кичәгә әзерләнгәндә сыйныфның яшь үзенчәлеге, үсеш дәрәҗәсе исәпкә алына.

Фасил Әхмәткә багышланган кичә

# Шушы яктан, шушы туфрактан ул.

**Укытучы чыгышы** (“Кукмара “ көе фонында ).,

Туган ягыбыз Кукмара тарихы ерак–еракларга барып тоташа. Урманнарга, елгаларга, оста куллы, җор телле кешеләргә искиткеч бай ул. Мондый җирлектә туган кешеләрнең, билгеле инде, җаны да, аңы да бай, матур була. Шуңа күрәдер инде районыбызда танылган шәхесләр-сәләхияткә ия кешеләр күп. Менә алар:

Безнең мәктәпне тәмамлаган күрше авыл егете 18 яшендә Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган, рейхстагка байрак эленгәннең икенче көнендә аны фотога төшереп алган Сабир Әхтәмов, Советлар Союзы Герое Фәхретдин Заһидуллин, Петр Воробьев, Николай Савин, Ибраһим Газизуллин.

Язучылар - Мәгъсүм Насыйбуллин, Фоат Галимуллин, Газинур Морат, Рифә Рахман, Заһид Мәхмүди, Рәшит Бәшәр.

Татарстанның халык рәссамы Мәхмүт Усманов.

Җырчылар - Мәрьям Рахманкулова, Ринат ИбраҺимов, Гали Ильясов, Алла Фадеичева, Нурәхмәт Мөхәмммәтҗанов.

Композиторлар –Фасил Әхмәтов һәм Рафаэль Билалов .

Бүгенге кичәбез якташыбыз – сихри моңнар чишмәсе, җырлар иҗатчысы Фасил ага Әхмәткә



**1 алып баручы**. Субаш – Аты авылында урта мәктәпне тәмамлагач, хыяллары аны Казанга алып килә. Химия – технология институтына укырга керә ул.

**3 нче укучы**. Хуш инде, авылым, хуш инде,
Күңелем нигәдер буш инде.
Кытыршы кулларның җылысын
Онытмый саклармын, хуш инде.

**4 нче укучы**. Авылымнан читкә мәшәкатьсез дөнья,
Гамьсез тормыш эзләп китмәдем.
Хәтеремдә саклыйм ашап үскәнемне
Бу кырларның арыш икмәген.

**2 алып баручы**. Азапланып үз – үзеңне эзләү башлана. Эзләп- эзләптә таба алмагач, военком янына барып, армия сафларынналуларын үтенә ул.

**1 алып баручы**. Һәм менә Баренц диңгезе. Хәрби корабль... аяусыз дулкыннар. Чатнама суыкта юпь-юеш киемдә тешләрен кысып үткәргән вахта сәгатьләре... госпиталь.

**5 нче укучы**. Беренче көн бүген без диңгездә,
Бу мәхшәргә ничек түзәргә.
Әллә диңгез суы, әллә маңгай тире
Ачыттырып керә күзләргә.

**2 алып баручы**. Аннан Казан. Авыру михнәтләре, инвалидлык ачысы. Чир белән аяк терәп тартышу, газапланулар. Һәм, ниһаять, күпме газаплар аша яңадан аякка басу шатлыгы.

**6 нчы укучы**. Язмыш сукмагыннан
Апам белән чыктык юлларга
Ә юлдагы яңгыр – бураннарны

Шәрилов.
Аның язмышы, тормышы тоташтан диярлек сынаулар, гел каршылыклар аша бара торган сикәлтәле юл булды. Май аенда Рәниф Шәриповка 50 яшь тулды. 50 яшь. Бу дөньяда яшәлгән 50 ел. Күпме әрнү, газап, кимсетелүләр, кимсенүләр сыйган аңа.

**1 алып баручы.** Әйткәнебезчә, 1950 нче елның 30 нчы маенда районыбызның матур бер төбәгендә- Аман-Оштарма авылында дәньяга килә ул. Кечкенәдән үк җыр-моңга гашыйк була. Әнисенең эчтән генә көйләп йөргән көе-“Рамай”ны яратып тыңлый малай.

(Татар халык көе “Рамай”яңгырый.)

**1 нче укучы**. Җилкендереп һәм тетрәтеп җанны,
Таян диеп шушы йөрәккә,
Моңнар фәрештәсе бер каурыен
Кадап китте нәни йөрәккә.

**2 алып баручы**. Гармунда уйнарга өйрәнә Рәниф. Дусларын да өйрәтә.Тик язмыш аңа сынауны бик иртә әзерләп куйган була. 12 яшьлек Рәниф дөм ятим кала. Бергә уйнап үскән дусларын , яланаяк йөргән ямьле Оштарма буйларын калдырып, Арча районы Субаш – Аты авылындагы балалар йортына китә ул.

**2 нче укучы**. Кимсетмәде Субаш –Аты,
Күпләп идек, күпсенмәде.
Яраларга кагылмады,
Күп сорашып төпченмәде.
Туган түгел , үги авыл,
Йөрәкләрдә калган авыл,
Асрамага алганнарны
Туган итә алган авыл.



багышлана.

1 укучы. Шушы яктан, шушы туфрактан ул .
Шушы урында килгән дөньяга.
Шушы юллар аны озатып калган
Тормыш дигән олы дәрьяга.
(Җыр “ Шушы яктан, шушы туфрактан без “).

2 укучы. Син Ерыклы Салтык кына идең,
Әмма нинди ир-ат үстердең.
Фасил белән булдың данлыклы,
И Кукмарам, Салтык-Ерыклы.

1 алып баручы.
1935 нче елның 23 нче маенда–табигать яшәргән, ямьләнгән чорда әтисе- тирә-якта дан тоткан гармунчы Әхмәтгәрәй агайны, әнисе–нечкә күңелле, хискә бай Бибисара апаны куандырып, уртак шатлык булып бер малай туа. Аңа Фасил дип исем кушалар.

2 алып баручы.
“Әти миңа музыкаль исем кушкан – фа һәм соль “ дип шаяртырга ярата еш кына Фасил ага үзе.
3 укучы.
Монда бар җир чәчәк кенә
Урманы, болыннары.
Һәрбер талы таныш миңа.
Газиз Өшен буйлары.
( “ Тал песие “ җыры башкарыла.)

1 алып баручы.
Сугыш башланганда, аңа алты яшь була. Хәвефле

сәфәргә кузгалыр алдыннан әтисе кулына тальян гармунын ала. “ Әллә гармунын да үзе белән алып китәргә җыена инде?” Фасилнең нәни йөрәге кысылып куя. Юк, әтисе улының күңелендә ниләр барын яхшы аңлаган икән . Улын кочагына алып сөйгәч, ул: “Мә, улым, миннән бүләк булсын. Мин кайтканчы, Туиш бабаң кебек уйнарга өйрән, ” - ди.

2 алып баручы.

Гармун кулына кергәч , тырыша Фасил, бик тиз өйрәнә. Тора - бара ул йөзек кашына әйләнә, аулак өйләр, мәҗлесләр –берсе дә аннан башка үтми. Биетә дә, җырлата да, елата да ул.

4 укучы.

Һай бу җырлар, һай бу халык моңы ,
Кайгыларың бераз онытыла.
Шаша йөрәк, актарыла хисләр,
Галәмнәргә күңел омтыла.
Шушы моңнар ,шушы җыр аһәңе
Яшәү бирә күпме җаннарга.
Кара төндә йолдыз булып яна,
Нурлар булып иңә таңнарда.

( “ Казан кичләре “ көе фонында )

1 алып баручы.

1952 нче ел. Булачак композитор Казанга килә. Музыка училищесына укырга керә.

5 укучы.

Казан, Казан....
Сиңа килдем менә.
Үз улыңдай кабул итсәңче.
Халкым моңын юлдаш итәр идем,
Шул дәрьяның серен чишсәңче.



Иң мөһиме- нинди генә хәлдә калсаң да, горурлыгыңны, ныклыгыңны, акылыңны югалтмаска кирәк.

Р. Шәрипов.

Бу егет, һичшиксез, шагыйрь, көчле шагыйрь.

С. Хәким.

Рәниф- Ф. Яруллин кебек, көймәсенең җилкәнен язмыш җилләре еккач та, көрәшүдән туктамаган, каләмен ишкәк, якты хыялларын канат итеп, тормыш диңгезендә йөзүен дәвам итүче көчле рухлы кешеләрнең берсе бит.

Ш. Мостафин.

**1 алып баручы.** Берәүләрне тормыш бер генә тапкыр сыный.Кеше дөнья зилзиләләренә каршы үзенең кечкенәдән үк җыелып килгән гайрәтен, ана сөте белән кереп,бөтен тамырларына таралган көчен куя. Куя да өстенә ябырылып килгән бөтен авырлыкларны бер селтәнүдә юкка чыгара. Икенчеләрне тормыш көн саен, сәгать саен сыный, үзенең сынауларын бер-бер артлы яудырып кына тора. Язмышларына баш имичә, тормышта үз урыннарын табу өчен көрәшүче, әйе, әйе, чын мәгънәсендә көрәшүче шәхесләр бар.

**2 алып баручы**. Шундыйларның берсе- безнең якташыбыз – Аман-Оштарма авылында 1950 елның ямьле май аенда дөньяга килгән шагыйрь Рәниф

Киткән аккошларың эзеннән.
Аккошларның ап-ак каурыйлары
Каберең өсләренә сибелгән.

Хор башкаруында “ Аккошлар “ җыры (Равил Фәйзуллин сүзләре) янгырый.

**Канат белән кем дә оча,**
**Син канатсыз очып кара**

Укучыларга җирле –төбәк күрсәткечләрен өйрәтү, якташ язучылар иҗатына таянып, үз төбәгең, анын күренекле шәхесләре белән горурлану хисләре тәрбияләүдә сыйныфтан тыш эшләрнең әһәмияте зур. Укучыларда әдәбиятны өйрәнүгә кызыксыну уята, аларның мөстәкыйльлеген һәм инициативасын үстерә, туган телебезнең байлыгын, нәфислеген сиземләүгә ярдәм итә андый эшләр. Н. Островский, Ф. Яруллиннар кебек көчле рухлы, язмыш авырлыкларына бирешми яшәүче якташ – шагыйребез Р.Шәриповның, композитор Фасил Әхмәтнең тормыш һәм иҗат юлына багышланган әдәби композиция шушы максатны күздә тотып төзелде.

Зал матур итеп бизәлә: уртага, чәчәкләр арасына Р.Шәриповның портреты куела; тормышы һәм иҗатын чагылдырган газета чыгарыла; плакатлар эленә. Плакатлар өчен түбәндәге өзекләрне файдаланырга мөмкин:



6 укучы.
Өздереп лә кемдер гармун уйный,
Көй агыла: “ Карашларың “, “ Онытмам “, “Люция “....
Фараз кылды халкың: бу егет дип
Моңнар тулы талантка ия.
(“ Мин гармун булыр идем “ җыры җырлана. Ф.Шафигуллин сүзләре)
7 укучы.
Бөтереп алды аны моң дәрьясы,
Уку урыны хәзер консерватория.
Аспирантура да тәмам булды.
Егет музыкаль белемгә ия.
8 укучы. Уйнадың да –тулды моңнар,
Тулды күңелләремә.
Күңелемне күмде гөлләр.....
Нур иңде гөлләремә!
Көйләреңне каян алдың,
Нинди тылсым беләсең?
Сандугачлар мәктәбендә
Укыдыңмы әллә син?
9 укучы.
Әй ул моңнар, әй ул изге моңнар
Дога булып иңә күңелгә.
Тыңлый халык, йөрәкләрдә - давыл.
Фасил исеме данга күмелә.
10 укучы.
Фасилнең сихри моңыннан
Җаннар җылына
Татар моңын күтәрде ул
Аккош юлына.
11 укучы.

Һәр талантның бар үз йолдызлыгы,
Булсын “Үлчәү”; Булсын “Җидегән”
Чиксез моң күгенә Фасыйл затны
Кукмарабыз озатып җибәргән.

12 укучы.

Талантлар күп бездә
Хәтеребездә
Нурлы – моңлы Фасыйл көйләре
Алар безгә керсез җан турында
Күпме илаһи сүз көйләде.

13 укучы.

Бала чактан үзе тыңлап үсте
Кошлар тавышын – моң симфониясен
Дөньякүләм дан китерде аңа
“Фәрит Яруллин” симфониясе.

14 укучы.

Татар моңын , татар җырын
Яңгыраттың син дөнья түрендә
Сихри моңың, якты исемең
Яшәр мәңге безнең күңелдә

15 укучы.

Хәтер дигән учакларның
Җил актара көлләрен
Көл астыннан калкып чыга
Күзе яшьле көйләрең.

2 алып баручы.

1998 нче елның 7 нче сентябрендә көйләр асылы Фасил аганың йөрәге тибүдән туктый. Ямьле яз аенда – бөтен дөнья чәчәккә күмелгән чорда дөньяга килгән асыл зат алтын көз көнендә безнең белән саубуллашып китеп тә барды.



1 алып баручы.

Фасил ага үзе: “Вакыты җиткәч, нишлисең, үзебез дә бу фани дөньядан китеп барырбыз. Ә яхшы җырның гомере озын, яхшы җыр бездән соң да калыр “, - дип язган иде. Җыр – көйләрең, моңнарың безнең күңелләрдә һәрвакыт сакланыр, буыннардан – буыннарга күчә барыр.

16 укучы.

Син бүген дә, Фасил, халкың белән
Күңелләрдә безнең бүген дә
Кара төндә кыйбла йолдызы син,
Көндез – Кояш татар күгендә.
Якты кояш - татар күңелендә!
Бүген дә!

17 укучы.

Күз суына, еллар уза..
Күңелдән китми хәсрәт..
Җитми җанга синең җырың,
Бәхил бул, моңлы Әхмәт.

18 укучы.

Ничә еллар үткәч кабат кайттың
Мәңгелеккә, бездә яшәргә.
Шушы якта синең исемең калсын
Ядкарь булып килер яшьләргә.

19 укучы.

Менә син дә китеп бардың , Фасил,
Киткән аккошларың артыннан
Ул аккошлар синең пакъ җаныңны
Саклап калыр җилдән , салкыннан.
Ашыгы-ашыга китеп бардың, Фасил,